Ф.С. Сәйфулина,

Казан федераль университеты, Казан

# Т.ГАЛИУЛЛИН ПРОЗАСЫ
# (“МӘКТӘП КИТАПХАНӘСЕ” СЕРИЯСЕ БУЕНЧА)

**Abstract.** This paper analyzes the stories T.Galiullina represented in the collection of the works of the author in the series "School Library".

Урта буын Тәлгать Галиуллины, әлбәттә, беренче чиратта абруйлы галим, гадел тәнкыйтьче, таләпчән професор буларак кабул итә. Бүгенге көндә, гәрчә остазыбызның проза өлкәсендә каләм уйната башлавына ике дистәдән артык вакыт узса да, безнең өчен ул галим-остаз булып калачак.

Кабул ителгән стериотиплардан читкәрәк чыгып төзелгән “Мәктәп китапханәсе” сериясендә тәкъдим итетлгән “Тәлгать Галиуллин. Сайланма әсәрләр” китабы, яшь укучыга җыентык авторын нәкъ менә язучы буларак тәкъдим итә. “Хикәяләр”, “Истәлекләр”, “Романнардан өзекләр”, “Публицистика һәм тәнкыйть” дигән бүлекләрдән торган бу җыентык, әле Галиуллин шәхесе белән таныш булмаган яңа буын – XXI гасыр укучысына язучы белән танышып, аның иҗат асылын бәяләргә мөмкинлек бирә.

Бу мәкаләнең төп максаты – китапка “Хикәяләр” исеме астында тупланган әсәрләргә идея-эстик ягыннан чыгып бәя бирүдән гыйбарәт.

Китапны ачып җибәрүче “Һавада татарин” хикәясе – беренче кәлимәләреннән үк укучыны язучы Т.Галиуллинның дөньяны кабул итү рәвеше белән таныштыра, авторның үзенчәлекле стилен таныта башлый. Бу хикәяне сөйләүче – тормыш тәҗрибәсе туплаган, студент еллары шактый еракта калаган җор телле олы яшьле кеше буларак төсмерләнә: “Җәмият, безнең халык баласы һавада оча. ... Дүрт тимер караватны биләгән дүрт татар токымы малайлары кәкре, йөнтәс, үкчәсе күптән су заты күрмәгән, мәгънәсез хуҗасы бер оегын салырга онытткан тәпиләрне, арзанлы яшел одеаллар куеныннан азат итеп,

идәнгә төшерергә мәҗбур итте”. Ләкин бу җиңел кәеф, “җиңел укуга” өмет тиз арада өзелә, чөнки әсәр тексты беренче юлыннан ук галимнәр “иттертекстуаль бәйләнешләр” дип атаган төшенчә белән таныштыра, укучыны үзенең “әдәби багажында” эзләнергә, уйланырга этәреш ясый.

Әлбәтә, 60 елларның ирекле, киң сулышлы, бер кысаларга да кермәскә, үзен чикләмәскә омтылган шагыйрьләре иҗаты, бу еллар шигърияте белән таныш булмаган укучы әсәрнең беренче фразасына ук салынган мәгънәне бөтен тирәнлеге белән аңламаячак. “1961 елның 12 апрель көне. Бу юлы инде, татар шагыйре әйтмешли, кефир шешәсендә гөлләр таңны күтеп алган иртәнге як”. Алга таба да хикәя кысаларында әдәбиятыбыз тарихына, аның аерым шәхесләре иҗатына, язмышына мөрәҗәгать кимеми, автор укучысын “интеллектуаль тонуста” тота, уйланып укуга көйли. “Тәрәзә арасындагы мамыкны эретер” дәрәҗәгә җиткергән озын кышны да исән-имин озатып җибәрдек. Студент тормышының илләм рәхәтлегенә күнегеп, тегеннән-моннан күчереп диплом ясап, дөнья бизәкләренә – хатын-кыз нәселенә чын-чынлап гашыйк булып, ара-тирә җавап хисләренә дә уралып, иң сәгадәт мизгелне кичергән вакытлар...”

Татар халкы үткәненә, совет иле тарихына караган, рус дәүләтенең татарларга карата күп гасырларга сузылган мөнәсәбәтенә бәйле аерым, искәртмәстән генә ташларган фразалар рәвешендә тәкъдим ителгән фикерләрнең дә ахыр килеп әсәрнең төп мәгүънәсен тоерга ярдәм итүен аңлыйсың. “Тукайның “Болгар” кунакханәсендәге кебек үк йозаксыз, шыксыз бүлмәгә сабакташыбыз Энвәр Мөхәммәтҗанов бәреп керә...”. Әлбәттә, бөек шагыйребезнең ятим язмышы хакында хәбәрдар булган укучы, әсәр эчтәлегендәге беренче карашка көлке кебек кенә тоелган сюжетның да, бик тирәндә яткан икенче катлам мәгънәсе – “подтексты” булуын тоемлый, чөнки автор бу изге исем белән кызык өчен генә уйнамас иде.

Авторның үзенчәлекле сөйләм рәвеше, һәр җөмләсендә учлап, киң күңел белән, байларча сибелгән тел энҗеләре укучыны үзенә беркетеп куя да, ахырга таба кечкенә генә бер вакыйга, аңарга геройларының мөнәсәбәте аша,

гомумтатар халкының күңен халәтен ачу кебек олы материяләргә килеп чыга. Күңелдә өмете, хыяллары тормышка ашмаган эшчән, тырыш татар халкының язмышын аңлаудан гаҗиз булган бер әрнү сызылып кала...

Ибрай Гаязы – китапта шушы исемдә тәкъдим ителгән хикәя герое. Галиуллин тудырган геройлар галереясының үзенчәлекле бер вәкиле. Әсәр бу очракта да язучы-вакыйгаларны тәкъдим итүченең истәлекләре рәвешен алган: “Хәтер тәрәзәсенә күз салам”. “Эре тешләрен елтыратып, эрекмән колагын тырпайтып, кабартма иреннәрен ерып” күз алдына килүче “атаклы урманчы Ибраһим карт улы Гаяз” тормышка, әйләнә-тирәгә бәясен үз каланчасы югарылыгыннан торып, бик дөрес итеп бәяли: “Син, каениш, язучы булып киттең, диләр. Нишлисең, башка эшкә ярамагач, синнән лесник чыкмый, урманда тиз адашасың, машина төзәтә белмисең, балта эшенә кулың ятып тормый, пич чыгара белмисең”.

Озын тормыш юлын узып, күпне күргән, күпне кичергән бу авыл карты һәр нәрсәгә үзенчә бәя бирергә күнеккән, нинди хәлдә калса да, аннан чыгу юлын үзенчә “үз файдасына” таба чишә белүче бу сәер, чамадан тыш булмаган хәйләкәр, балаларча беркатлы, шуның белән бергә ясалмалылыкны, масаюны кабул итми торган бу карт халкыбызның Хуҗа Насретдин тибындагы бер яклы гына бәя белән ачып, аңлатып булмастай үзенчәлекле герой. Шәһәргә китеп бераз гына һаваланганыңны күрсә дә, тиз арада, бер сүз белән “туган туфрагыңа” кайтарырлык тапкыр да, туры да тел иясе. “Колакларым картайды, күзләрем талчыкты” дигән картның “Энем, кибет янында машина тора. Шуннан чыккан кара кәчтүмле, акмы, сарымы күлмәкле кеше Шомырт Нәгыйм малае түгелме,”- дип фикерен дәвам иттергән картның икенче җөмләсенә: “Ерактан мин чыннан да начар күрәм. – Танымыйм, Гаяз абый,”- дип, акланган кебек җавап бирергә өлгермисең, алдагы сүзләре беләнул сине бөтенләй коралсыз калдыра:

- Мин, энем, шыларны тану түгел, бөтенләй күрмим”.

Авыл картының йөгерек фикеренә, тормыш фәлсәфәсенә тел шартлатасы гыны кала.

“Тормышчан бетем” хикәясе җиңелчә юмор белән башланып, геройларның үзара мөнәсәбәтләрен сурәтләүдә сатира, иронияге алымыннан да файдаланылып язылган әсәр. Әсәрнең сюжет линиясен үтә дә тормышчан булган язучы-мөхәррир мөнәсәбәтләре тәшкил итә. Хикәянең бусы да тормыштан алынган, ләкин кат-кат кабатланып төсе җуелмаган чагыштыруларга бай. “Хикәя сырлау кебек керемсез шөгыльгә алынган кемсәнең” мөхтәрәм гәзитнең бүлек мөдирен сагалап йөрүе автор тарафыннан “күгәрчен аулаган җирән мыеклы мәчедәй” дип сурәтләнсә, бүлек мөдиренең кыланмышлары исә хикәяче карашынча “чит мәмләкәтләр белән мөнәсәбәтләр өчен җаваплы кешедәй кыйланып, телефонда ябыша” дип тәкъдим ителә, шул ук бүлек мөдире бәясендә баш мөхәррир исә “сөзсә озакка суза торган мүкләк сыер кебек” дип чагылыш таба. “Маңгаена “М” хәрефе кадакланган бүлмәдән ары китмәгән елдырым вә фәһемле адәм” булган бүлек мөдире “шома балык төсле кулдан ычкына белә”.

Шушындый катлаулы сәбәп-максат бәйләнешләрен бәян иткәннән соң, автор төп каршылыкны сурәтләүгә күчкәнче, геройларының портретына да игътибар бирә. Бу очракта каләм тибрәтүченең сурәтен бирүне автор “үткен күзле”, “колга буйлы” фразалары белән чикләсә, мөдирне исә җәелеп, тәфсилләп сурәтли һәм бу очракта да чагыштыруларны мул куллана: “Ак озын муенны гыйнвар карыдай ап-ак күлмәк дәвам итә. Чем-кара чәчле кечкенә башы, каймакка төшкән чебен кебек, ерактан күренеп тора”. Болардан тыш соңрак геройның кәефенә дә ачыклык кертелә: “Бүлек мөдиренең кәеф-сихәтләре әгъла булуы түгәрәк йөзенә, почык борынына, хәтта кыска керфекләренә хәтле бәреп чыккан”.

Әсәр вакыйгаларында турыдан-туры катнашмыйча, аталучы герой сыйфатында гына тәкъдим ителсә дә, “Балалар уенчыгы фабригында эшләүчеләрнең шигырьләр бәйләме” тән күзәнәкләренә мәтрүшкәле себеркедәй хуш килгән баш мөхәррирне укучыга күз алдына китерү кыенлык тудырмый.

Төп каршылык, әлбәттә, хикәяченең чираттагы әсәрен бастыру-бастырмау мәсъәләсе җирлегендә туа. “Төшке аш астына, уртасына һәм тәмамына салып

калдырган затлы хәмер, алтын балдакны бизәгән фирәзәдәй, яшәүгә мәхәббәтне бермә-бер арттырган" бер мизгелдә, әлбәттә, аның кемнеңдер чиле-пешле әдәби әсәре турында фикер алышасы килми. Шулай да "чандыр сыйраклы" "кычыткан чыпчыгы"ннан котыла алмаячагын аңлаган бүлек мөдире "кәгазъ әрәм итүченең өч ай өстәл тартмасында яткан" хикәясен искә алырга мәҗбур була. Әсәрнең эчтәлеген, сюжет линиясенең тормышчан булуын бәяләү дә шушы рухта дәвам итә. Әсәрнең "тормышчан бетеме" булмавы төп мәсъәләгә әйләнгәч, хикәяче үзен көтелмәгәнчә кыю тота һәм хикәясен бастыру өчен бөтен мөмкинлекләрдән дә файдалана, мөдирнең күзенә карап ялганга кадәр барып җитә.

Язучы Т.Галиуллин иҗатындагы бу әсәр әдәби тәнкыйтьченең рухына туры килеп торган юмор-сатира жанрына караган әсәр үрнәге буларак каралырга хаклы.

Кинаяле сөйләм белән, тәкыйди характерда язылган әсәрләрдән тагын авторның "Өмет бухтасы" әсәре хикәя булудан бигрәк, авторның татар әдәбиятының торышына тәнкыйди-иронияле караш буларак кабул ителә. Язма "Гомер юлымның башында ук поэзиягә каныктым" дип тәнкыйтҗче-галимнең кереш сүзе белән башланып китә һәм үз заманы әдәбияты торышына шарҗ тосмерен ала.

Язычының "Төш" хикәясе исә шундый ук кинаяле сөйләм ысулы белән тәнкыйтьче-язучының туган якларына мөнәсәбәтле өмет-хыялларын чагылдырыла. Якташы – беренче профессинал режиссер Габдулла Кариев исемендәге урам, шул урамда ачылачак милли гимназия турындагы тормышка ашмас хыялларын төшендә күргән тәнкыйтьче, хәтта татар башкаласында да халкыбызның горурлыгы булып торырлык асыл затларына һәйкәлләр кую зур кыенлыклар белән генә башкарылуына ачына.

Поэтикасы, төзелеше ягыннан камил, бик үзенчәлекле тормыш ситуациясенә корылган сюжетлы, җор, төртмә телле, кызыксыну белән, уйланып укыла торган бу әсәрләр тирә-яклары тумышларыннан мәгълумәти чаралар белән әйләндереп алынган замана балаларын чын әдәби мөхиткә тарта

алырына өмет белән төзелгән бу җыентык үз укучысын табыр дип ышанасы килә.